// Мәктәп хәбәрчесе

Түбән Майна урта мәктәбе газете

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

№9 (№12) ноябрь 2019 ел

/Өлкәннәр киңәше /

## Сөйләм әдәбе турында

Яхшы сүз яшәртә көч бирә
Яхшы сүз шифалы, тылсымлы
Юа ул яраны, борчуны.
Яман сүз агудай әшәке,
Хәтта ул корыта чәчәкне
Яман сүз еландай сугыла,
Ул салкын бозны да туңдыра .
(Г.Латыйпов)

Тел кешелекнең аралашу чарасы. Аның мөмкинлекләре бик күп. Тулысынча дөрес итеп, урынлы итеп кулланабызмы без туган телебезне. Безнең телебез – татар теле. Бай, аһәңле, матур тел ул. Гасырлардан гасырларга килгән, бары тик үз телебезгә генә хас булган матур сүзләр бихисап. Ә без, бүгенге заман балалары, телебезнең мөмкинлеген файдаланабызмы? Аның асылын югалтмыйбызмы? Телебезне башка телдән кергән сүзләр белән пычратмыйбызмы?

Бүгенгесе көндә мәктәп укучыларының бер-берсе белән сөйләшүе, аралашуы берникадәр үйланырга мәҗбүр итә. Телефоннар заманында, игътибар белән карасак, аралашу кыска гына смслар, открыткалар ярдәмендә генә бара. Авыл мәктәбе булуга карамастан, уку кабинетлары барлык фәннәр буенча да заманча технологияләргә таянып җиһазланган, интернетка чыгу теләсә кайсы эш урыныннан каралган. Укучылар да теләгән вакытта интернетка чыгалар, төрле проектлар, эзләнү эшләре алып баралар, буш вакытларын да интернет челтәреннән башка уздыра алмыйлар. Нәтиҗәдә балаларның бер-берсе белән аралашуы интернет челтәрендә генә башкарыла, алар үзләренең фикер йөртү сәләтләрен югалталар, күп вакыт сарыф итәләр. Бу сәламәтлеккә дә бик зур зыян сала. Һәрвакыт менә шулай аралашкач, кеше белән очрашканда күп укучылар югалып кала, сөйләшү өчен уртак сүзләр таба алмый азаплана. Берничә кешедән торган төркемдә берьюлы 3-4 кешенең сөйләп торганын да күргәнем бар. Бу инде этикет кагыйдәләрен бозу, әңгәмәдәшеңне ихтирам итмәү. Я булмаса, бер кеше артык каты итеп кычкырып сөйләү дә матур түгел. “Бер сүз кирәк кеше җанын дәваларга, бер сүз кирәк кеше җанын яраларга”- дип җырлана җырда. Әйдәгез әле, кеше җанын дәвалый торган сүзләр генә сөйлик. Бер беребезне рәнҗетүдән саклаыйк!

Кеше тормышында аралашу – шәхес буларак үсү өчен иң мөһим шарт икәнен онытмасак иде. Әйдәгез әле, укучым, телефоннарны бер читкә куеп, әдәби китап укыйк. Классик язучыларыбызның әдәби хәзинәсенең байлыгын, телебезнең барлык нечкәлекләрен кулланып иҗат ителгән әсәрләрдән “бераз авыз итик”. Шулвакыт тормышка, дөньяга карашыбыз киңәер иде. Иптәшебез белән аралашу да сөйләм әдәбенә буйсыныр иде дә, бер-беребезне тыңлап кына сөйләшергә күнегер идек.

*Гөлнур Кадыйрова, рус теле һәм әдәбияты укытучысы*




## 29 ноябрь – Әниләр көне

Әни дигән исем белән
Бала кемне йөртә соң?
Шул исемгә бар дөньяның
Беләсеңме сыйганын?

Әни бирә газизенә
Һичкем бирмәгәнне дә.
Баласының хәлен белә
Беркем белмәгәндә дә.

Җаны белән тоеп яши
Һәрбер тын алуыңны.
Йөрәк белән көтеп ала
Исән-сау кайтуыңны.

Алтыда да, алтмышта да
Бала була алсак иде.
Аның өчен газизләрнең
Кадерен белсәк иде.

***/Рәсми хәбәрләр/***



30 октябрь көнне, көзге каникул көннәрендә, Түбән Майна урта мәктәбендә мәктәп яны **"Дуслык" лагереның** көзге сменасы эшли башлады. Лагерьга 25 тәрбияләнүче йөрде. Укучылар төрле юнәлештә эшләделәр. Башлангыч һәм урта сыйныфлар сыйныф җитәкчеләре белән эшләгән булсалар, чыгарылышлар имтиханга әзерләнделәр. Шул көннәрдә лагерьда **ЮХИДИ хезмәткәрләре белән очрашу** булды. Очрашуда ЮИД отряды кунакларга үзләренең чыгышлары күрсәттеләр. Лагерь эшчәнлеге кыска араларда булса да, укучыларга мавыктыргыч итеп һәм файдалы оештырылды. Ашханәдә дә пешекче апалары тәмле ризыклар белән сыйладылар.

5 нче ноябрь көнне мәктәпнең барлык хезмәткәрләре өчен янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча укулар узды.



II чирек башында фән олимпиадаларының мәктәп туры төгәлләнеп, район туры башланып китте. 13 укучыбыз район олимпиадаларында катнашачак. Аларга уңышлар теләп калабыз.

11 ноябрь көнне мәктәптә **"Сүзлек көне"** үткәрелде. Укучыларның сүзлек куллана белүләрен тикшерү, танып белү активлыгын арттыру максатыннан үткәрелгән чараны рус теле укытучысы Нәҗметдинова Рушания апа оештырды.

26 ноябрьдә районда **"Күңелле стартлар"** ярышында да укучыларыбыз көч сынашты. Кызганычка каршы, безнең команда алдынгы урыннарга ирешә алмады.

29 ноябрьдә авыл мәдәният йортында уздырылган **"Әниләр көне"**нә багышланган чарада укучыларыбыз актив катнашты.

***/Безнең сәфәрләр/***

## *"Иделем акчарлагында"*



Быелгы уку елы башында республикакүләм **"Иделем акчарлагы"** бәйгесенең нигезләмәсен күреп, үземнең иҗат иткән шигырьләремне җибәреп карарга булдым. Бу конкурс "Идел" яшьләр үзәге тарафыннан оештырыла. Бераз вакыт узганнан соң, минем конкурс шартларын үткәнемне хәбәр итеп, Казан шәһәренә чакыру килде. Шулай итеп, 25-27 ноябрь көннәрендә мин бу иҗади үзәктә катнашырга киттем.

"Иделем акчарлагы" инде 19 ел буе иҗат белән шөгыльләнүче яшьләрне барлау максаты белән эшли. Ниһаять, мин дә бу үзәктә! Беренче көнне безне кунакханәгә урнаштырдылар, танышырга, ял итеп алырга вакыт биргәннән соң, катнашу бүләге итеп, Кәрим Тинчурин исемендәге театр бинасында бөек татар шагыйре Дәрдмәнднең тууына 160 ел тулу уңаеннан оештырылган иҗади кичәгә алып бардылар. Төнге шәһәрне урап кайтканнан соң, иҗади дуслар белән төрле уеннар уйнаттылар.

Икенче көнебез дә минутлап оештырылган иде. Галиәсгар Камал исемендәге театрда тамаша, чын шагыйрьләр белән очрашу булды. Луиза Янсуар, Айгөл Абдрахманова үзләренең иҗат биографияләрен сөйләп, тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, төрле идеяләре белән бүлештеләр. Шуннан соң узган елгы Гран-При ияләре белән дә танышу бәхетенә ирештек.

Кичен янә театрда! Бу юлы инде атаклы Камал театры бинасы безне матурлыгы белән киң колачлап каршылады! Биредә Норвегия драматургы Й.Фоссеның "Җәйнең бер көне" дип аталган театрын карадык.

Сәфәребезнең соңгы көнендә бүләкләү тантанасы булды. Аннан калган вакытыбызны Тукай музеенда үткәрдек. Бөек шагыйребез турында тагын да хатирәләр туплап, бүләкләр барлап, күңелләребезгә иҗат рухы салып яңа танышлар белән аерылыштык. Бу конкурста катнашуыма мин бик шат!

***Әминә Туктамышева. VIII сыйныф укучысы***

**/ТАССРның 100 еллыгына/**

## Түбән Майнада балалар бакчасы

Түбән Майнада даими эшләүче балалар бакчасы ачу ихтыяҗы күптәннән өлгерүгә карамастан, ул 1978 елдан гына эшли башлый. Аңа кадәр мәктәп яшенә җитеп килүче балаларны укуга әзерләү өчен махсус түгәрәкләр оештырыла. Биредә балалар каләм-карандаш тотарга, дәфтәрдә язу күнекмәләренә өйрәтелә. Мәсьәлән, без укырга керер алдыннан 1975-1976 елның кышында шундый әзерлек төркеменә йөредек. Бу эшне өлкән яшьтәге укытучы Шакирова Зәйнәп апа алып барды. Әлеге укулар җомга көннәрне уздырылганлыктан, без аны “җомгага йөрү” дип атый идек.

Балалар бакчасы өчен элек башлангыч сыйнылар укыган һәм ашханә буларак файдаланылган “кечкенә мәктәп” дип йөртелгән бина тапшырыла. Ул чорда укучылар саны кимү сәбәпле, башлангыч сыйныфлар мәктәпнең төп бинасына, ә ашханә шул елны яңа өлгергән кирпеч бинага күчерелә. Бакча бинасы иске булу сәбәпле, хезмәткәрләрдән аны җылыту һәм ремонтлап тәртиптә тоту өчен күп эш таләп ителә. 1995 елда кирпечтән яңа котельная бинасы төзелеп, балалар бакчасы газ ягып җылытыла башлый. 1980 еллар ахырыннан бирле бакчаның кухнясы элек мәктәп остаханәсе һәм трактор кабинеты булып торган аерым өйдә эшләп килә. Бу бина тикшерү органнары тарафыннан яраксыз дип табылгач, 2006 елда кухня мәктәп остаханәсенең бер бүлмәсенә күчерелә. Шул ук елны балалар мәйданчыгы да тулысынча яңадан ясалды.

Бакчаның беренче мөдире Шәрифуллина Сания апа була. Тәрбияче итеп, яңа укуын тәгәлләп кайткан Иске Әдәм авылы кызы Гимадиева Һәдия апа алына. Тәрбияче ярдәмчесе булып Гафиятуллина Миңсылу, пешекче булып Гатиятуллина Нәгыймә апалар эшлиләр.

1980 еллар башында бакча хезмәткәрләре коллективы тулысынча диярлек алышына. 1981 елда бакча белән яңа авылга кайтып төпләнгән Исмәгыйлева Асия апа җитәкчелек итә башлый. Ул бу вазыйфада 2005 елда лаеклы ялга чыкканчыга чаклы эшләде. 1980 еллар дәвамында бакчаның төп вазифасы булган тәрбияче булып төрле апалар эшләп киттеләр. 1989-2008 елларда тәрбияче ярдәмчесе булып Гафиятуллина Флера апа эшләде. Шул елларда пешекче булып Гобәйдуллина Гөлсинә апа хезмәт куйды. Аны 2004 елда Сәгъдиева Рәмзия алыштырды.

Бакча тарихының 1990 еллар башыннан алып 2012 елга чаклы булган чорын тәрбияче Фәридә апа дәвере дисәк тә бик урынлы булыр. Авылыбыз балаларын тәрбияләүдә Фәридә апа бөтен күңелен биреп хезмәт итте. Ул елларда бакчага йөргән балалар аны һәр яктан якты хәтирәләр белән искә алалар. Кызганычка каршы, 2012 елның көзендә, каты авыру нәтиҗәсендә, Фәридә апа вафат булды. Игелекле хезмәтләре өчен Аллаһы Тәгалә урынын җәннәттә кылса иде.

2008 елда яңа мәктәп салу буенча эшләр башланып киткәч, балалар бакчасын да мәктәп белән бер бинада булдыру планлаштырылды. Нәтиҗәдә, 2014 елда мәктәп белән бергә, балалар бакчасы да яңа заманча бинада эшли башлады. Балалар бакчасының соңгы җитәкчесе Хәйруллина Рузилә булды. 2015 елда, райондагы белем бирү оешмаларын реструктуризацияләү барышында, Түбән Майна балалар бакчасы аерым оешма булудан туктап, мәктәп составына кертелде. Шулай итеп, бакча тарихының яңа этабы башланды.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

**/Истәлеккә –фотосурәт/**



Бу фотода - Түбән Майна балалар бакчасы коллективы. 1979 елда төшерелгән.

Арткы рәттә (сулдан - уңга) хезмәткәрләрдән Гатиятуллина Нәгыймә, Шәрифуллина Сания, Гимадиева Һәдия, Гафиятуллина Миңсылу апалар.

Тәрбияләнүчеләр - 1972-1977 елда туган балалар.

**/Күренекле шәхесләр/**

## Авылдашыбыз – мөгаллимнәр династиясе вәкиле



Гәзитебезнең беренче санында ук гомерләрен авылыбыз балаларын укытуга багышлаган Хәлиулла абый һәм Шәрифә апа Исмәгыйлевларга багышланган мәкалә урнаштырган идек. Бу номерда аларның хезмәт традициясен дәвам иткән уллары, ветеран укытучы Исмәгыйлев Рафик абыйдан алган интервьюны бирәбез.

**- Рафик абый, укытучы булу теләге Сездә кайчан һәм ничек туды?**

- Минем әти-әниемнәр гомерләрен балалар укытуга багышладылар. Алар үрнәгендә мин дә шушы һөнәрне сайлаганмын.

**- Укытучы белгечлегенә кайсы уку йортында укыдыгыз?**

- Мин Казан Дәүләт педагогика институтының физика-математика факультетын тәмамладым. Хәрби хезмәтне үтәгәннән соң, 1974 елдан 2007 елга кадәр укытучы булып эшләдем. Димәк, 34 ел гомерем шул мәктәп, балалар арасында үткән. Эшләү дәверемдә директор вазифасын да башкардым. Үзебезнең туган мәктәптә генә түгел, күрше район мәктәпләрендә дә директор да, укытучы да булып эшләү насыйп булды.

**- Нинди фәннәрдән белем бирдегез?**

- Авыл мәктәбендә мин физика, математика укыттым. Укытучылар җитмәү сәбәпле, химия белән биология, хезмәт дәресләре дә, астрономия фәнен дә укытырга туры килде.

**- Рафик абый, хезмәт юлыгызда төрле предметлар да укыткансыз, җитәкчелек тә иткәнсез. Сез эшләгән чорда нинди авырлыклар була иде?**

- Җиренә җиткереп башкарам дигән теләсә кайсы эштә авырлыклар була, әлбәттә. Ул чор кыенлыкларын санаганда, сыйныф бүлмәләре салкын була иде. Озак еллар дәвамында мәктәп бинасы мичләргә утын ягып җылытылды. Бина иске булганлыктан тиз суына иде. Кышка җитәрлек утынны укытучы ир-атлар – Замир абый, Сергей Николаевичлар белән бергә җәй буе әзерли идек.

Тагын шуны да әйтәсем килә, безнең авыл район үзәгеннән ерак урнашканлыктан, мәгариф бүлегенә барып йөрү бик авыр булды. Чөнки юл салынмаган, транспорт юк дәрәҗәсендә. Шулай булса да яратып башкарган хезмәт булганга зарланмадык. Күмәк эш тау күчерә, ди халык, шул юл белән бергәләшеп ул авырлыкларны җинә идек.

**- Укыту өчен кирәкле әсбаплар җитәрлек булдымы?**

**-** Укучыларга кирәкле уку әсбаплары да җитмәү очраклары булгалады. Ләкин химия-биологиядән реактивлар, төрле тәҗрибә ясау өчен препаратлар белән бик әйбәт тәэмин итә иде район мәгариф бүлеге. Ул вакытта директор булып эшләгән Рифкат Габдрахман улы бик нык әйбәт эшләде һәм барлык уку әсбапларын алып кайтып бирә иде.

**- Рафик абый, әңгәмәгез өчен зур рәхмәт. Сезгә сәламәтлек, озын гомер теләп калабыз.**

***Әңгәмәне VIII сыйныф укучылары Виктория Нукина һәм Зөлфирә Сафиуллина язып алды***

**/Безнең спорт/**



3 ноябрь көнендә Яшьләр һәм спорт үзәгендә Аксубай районы яшьләре арасында Халыклар бердәмлеге көненә багышланган шахмат турниры уздырылды. Өстәмә бүләк буларак, җиңүчеләргә 2020 елның 1 яртыеллыгына “Авыл таңнары» газетасына бушлай яздыру мөмкинлеге бирелде. Турнирга безнең мәктәп данын якларга 5 егет барды: Гафиятуллин Фаил, Хәйруллин Айназ, Нурматов Муса, Хәйруллин Данил, Нурматов Халид. Ярыш бик кызу иде, чөнки барлык катнашучылар да тигез дәрәҗәдә көч сынашты. Катнашучыларның ин олысы 1981 елгы булса, иң кечкенәсе 2010 елгы иде. Нәтиҗәдә, шахматчларның иң кечкенәсе, шул исәптән безнең мәктәп укучысы булган Фаил Гафиятуллин 3нче урынга лаек булды. Киләчәктә аңа һәм калган барлык егетләребезгә алда буласы турнирларда уңышлар телибез!

Ноябрь аенда бакча төркеменнән **Нурматова Асия**, V сыйныфтан **Хайруллин Айназ,** VI сыйныф-тан **Гафиятуллин Самат,** IX сыйныфтан **Ахметова Нәзирә, Насыйрова Сара,** XI сыйныфтан **Сафиуллина Динәнең** туган көннәре булып узды.

Кадерле дуслар! Сезне туган көннәрегез белән котлыйбыз! Сезгә тән һәм рух сәламәтлеге, тәртипле, тырыш, уңган шәхесләр булып үсүегезне телибез!




Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина
Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина
Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова